СОВЕТ КУЮК-ЕРЫКСИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Вахитова, д.1а, с. Новый Кумазан,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422151

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КӨЕК-ЕРЫКСА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Вахитов ур., 1а нче йорт, Яңа Комазан авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422151

тел.(факс): (85563) 3-67-33; e-mail: Kuer.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

КАРАР
№1-54

РЕШЕНИЕ
08.09.2020

«Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары һәм «Көек-Ерыкса авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары арасында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында килешүләр төзү тәртибен раслау хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Көек-Ерыкса авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1.Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының « Көек-Ерыкса авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы «Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары арасында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында килешүләр төзү тәртибен 1 нче кушымта нигезендә расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның pravo.tatarstan.ru рәсми порталында урнаштырырга.

Мамадыш муниципаль районы
Көек-Ерыкса авыл җирлеге башлыгы Ф.Р.Шәйхетдинов

Мамадыш муниципаль
районының Көек-Ерыкса
авыл җирлеге Советының
2020елның 08 сентябре
1-54 карарына
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының « Көек-Ерыкса авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы «Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары арасында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында килешүләр төзү тәртибен

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының « Көек-Ерыкса авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары (алга таба - җирлек) һәм Татарстан Республикасы «Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары (алга таба - Район) арасында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен тапшыру турында килешүләр төзү тәртибе «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон) нигезендә эшләнгән.

2. Җирле үзидарә органнары Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә Җирлек бюджетыннан бирелә торган бюджетара трансфертлар хисабына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча үз вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыруны тапшыру турында Районның җирле үзидарә органнары белән килешүләр төзергә хокуклы.

Шул ук вакытта районның җирле үзидарә органнары җирлек территориясендә авыл җирлегенең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрен хәл итү вәкаләтләрен «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча районның җирле үзидарә органнарына аерым вәкаләтләр бирү турындагы килешүләр нигезендә гамәлгә ашыра.

3. Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен җирлекләрнең һәм районның җирле үзидарә органнары тапшыра ала.

5. Авыл җирлеге башкарма комитеты үз инициативасы белән яисә районның җирле үзидарә органнары инициативасын карап, 30 көн эчендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча аерым вәкаләтләрне тапшыру турында җирлек Советы Карары проектын әзерли.

6. Авыл җирлеге башкарма комитеты вәкаләтләрнең бер өлешен җирлек Советына норматив хокукый актлар керткәндә билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда тапшыру турында җирлек Советы Карары проектын кертә.

7. Җирлек советы җирлекнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрен хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен район җирле үзидарә органнарына тапшыру

турында Карар кабул итә һәм кабул ителгән карарны район җирле үзидарә органнарына карауга җибәрә.

8. Авыл җирлеге советы карарын уңай карау нәтиҗәсендә җирлек җирле үзидарә органнары һәм районның җирле үзидарә органнары арасында килешү төзелә.

Күрсәтелгән килешү билгеле бер срокка төзелә, аның гамәлдә булуын туктату нигезләрен һәм тәртибен билгели торган нигезләмәләр, шул исәптән вакытыннан алда, тапшырыла торган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле бюджетара трансфертларның әлеге өлештә күрсәтелгән еллык күләмен билгеләү тәртибен, шулай ук килешүләрне үтәмәгән өчен финанс санкцияләрен күздә тотарга тиеш.

Килешү проектын эшләү өчен, һәр яктан бертигез санда вәкилләр кертелеп, эш төркеме төзелергә мөмкин. Эш төркеме үз эше нәтиҗәләре буенча килешү проектын әзерли, ул ике якның мәнфәгатьләрен дә максималь исәпкә ала.

9. Җирлек Советы җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны Районның җирле үзидарә органнарына тапшыру турында карар проектын кире каккан очракта, инициативаны җибәргән район үзләре башлап җибәргән мәсьәләне карау нәтиҗәләре турында хат юллана.

10.Килешүдә каралган вәкаләтләрне үтәү өчен кирәкле финанс чаралары бюджетара трансфертлар рәвешендә бирелә.

Бюджетара трансфертларны максатчан файдаланмаган очракта, алар Җирлек бюджетына ун көн эчендә кайтарылырга тиеш.

Тапшырыла торган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле бюджетара трансфертларны тапшыру максатларында бюджет законнары нигезендә тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле чаралар каралган район һәм җирлекләр бюджеты турындагы карарда үзгәрешләр кертелә.

Тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга Җирлек бюджетыннан бирелә торган бюджетара трансфертларны формалаштыру, санап чыгару һәм исәпкә алу Россия Федерациясе бюджет законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Вәкаләтләрнең бер өлешен гамәлгә ашыру өчен бирелә торган финанс чаралары ай саен тигез өлешләр белән күчерелә, әмма бер үк вакытта финанс чараларының бөтен суммасын күчерергә мөмкин.

11.Вәкаләтләрнең бер өлешен гамәлгә ашыру өчен кирәк булганда, түләүсез вакытлы файдалану шартнамәсе нигезендә муниципаль мөлкәт тапшырыла.

Түләүсез файдалану шартнамәсе ашыгыч рәвештә һәм Килешүнең гамәлдә булу срогына төзелә.

12.Күрсәтелгән килешүләр нигезендә тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен Районның җирле үзидарә органнары муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы карары белән каралган очракларда һәм тәртиптә үз матди ресурсларыннан һәм финанс чараларыннан файдаланырга хокуклы.

13. Җирлекнең вәкаләтләрен тапшырган җирле үзидарә органы тапшырылган вәкаләтләрнең үтәлешен тикшерә, тапшырылган финанс чараларыннан һәм матди ресурслардан файдалану турында кирәкле мәгълүмат соратып ала.

14.Килешүнең гамәле вакытыннан алда туктатылырга мөмкин:
- Яклар килешүе буенча;
- берьяклы тәртиптә, Якларның берсе үз йөкләмәләрен үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән очракта.
15. Килешүнең гамәлдә булуы вакытыннан алда туктатылган очракта, тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы Районның җирле үзидарә органы файдаланылмаган финанс чараларын һәм вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен тапшырылган матди ресурсларны һәм мөлкәтне кире кайтара.
16. Килешүне үтәүгә бәйле бәхәсләр сөйләшүләр уздыру һәм башка килештерү процедуралары юлы белән хәл ителә. Бәхәсне сөйләшүләр уздыру яки килештерү процедуралары уздыру юлы белән хәл итү мөмкин булмаган очракта, ул законнарда каралган башка тәртиптә каралырга тиеш.